КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 февраль г.Казань № 97

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу турында

Дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында яллаучы вәкилгә хәбәр итү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренә 30 көн эчендә дәүләт учреждениесе уставына «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^3$ статьясы нигезендә учреждениенең коррупцияне кисәтү буенча, шул исәптән учреждение җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга

салу буенча чаралар күрү йөкләмәсен күздә тоткан үзгәрешләрне кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 13 февраль, 97 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясен (алга таба – Комиссия) төзү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең (алга таба – учреждениеләр җитәкчеләре) вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамәләрен карап тикшерү буенча аның эш итү тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп бурычы – учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турында законнар үтәлешен тәэмин итүдә булышлык күрсәтү.

4. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алган мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген булдырмый торган итеп төзелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

5. Комиссия составына Комиссия рәисе, аның рәис урынбасары һәм әгъзалары керә. Комиссия составына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсенә караган кадрлар бүлеге, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе вәкилләре, шулай ук килешү буенча Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле һәм эшчәнлеге дәүләт хезмәтенә бәйле фәнни оешмалар һәм мәгариф оешмалары вәкилләре керә.

6. Комиссия эше учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамәләре керүгә карап үткәрелә торган утырышларда гамәлгә ашырыла.

7. Комиссия утырышы Комиссия рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрыннан (алга таба – эш бирүче вәкил) хәбәрнамә алынган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.

8. Комиссия утырышында Комиссиянең гомуми составыннан кимендә яртысы катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала. Утырышны – рәис, ә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары алып бара. Комиссия утырышына Комиссия составына керми торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәләре вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия утырышына чакырылган затларның исемлеге Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Карарлар Комиссия тарафыннан утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

9. Учреждение җитәкчесе үз хәбәрнамәсен карап тикшергәндә катнашырга һәм андагы белешмәләрнең эчтәлеге буенча аңлатмалар бирергә хокуклы.

10. Хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

учреждение җитәкчесе тарафыннан вазыйфа бурычлары башкарылганда мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

учреждение җитәкчесе тарафыннан вазыйфа бурычлары башкарылганда шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта Комиссия учреждение җитәкчесенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

учреждение җитәкчесе тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре үтәлмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия яллаучы вәкилгә учреждение җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

11. Комиссия карары утырыш үткәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүче тарафыннан кул куела. Комиссия карарлары яллаучы вәкил өчен тәкъдим итү характерына ия була.

12. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш үткәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә яллаучы вәкилгә, шулай ук учреждение җитәкчесенә җибәрелә.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 13 февраль, 97 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында яллаучы вәкилгә хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре (алга таба – учреждениеләр җитәкчеләре) тарафыннан вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Премьер-министрына (алга таба – яллаучы вәкил) хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра.

2. Вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә учреждение җитәкчесе тарафыннан, мондый кызыксыну барлыкка килгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча язма рәвештә яллаучы вәкилгә җибәрелә.

3. Яллаучы вәкиле хәбәрнамә алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә җибәрә. Хәбәрнамә әлеге Комиссия турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында яллаучы вәкилгә хәбәр итү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Премьер-министры _________________ га (гә)
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
________________________ тан (тән)
(биләнә торган вазыйфа, учреждение исеме)

Вазыйфа бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазыйфа бурычларын башкарганда миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерә алган (*кирәкле сүз астына сызарга*) шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар: _________________
___________________________________________________________________.

Шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яки ясый алган вазыйфа бурычлары:
___________________________________________________________________.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________________
___________________________________________________________________.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхси катнашырга җыенам/җыенмыйм (*кирәкле сүз астына сызарга*).

| ________________ | ________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаны таркатып язу) |

__________________________